**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

2023 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Тымытык авыл җирлеге Тымытык торак пунктында гражданнардан үзара салым кертү турында

**28 октябрь 2022 ел** **№2**

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принципларына турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Тымытык авыл җирлеге Тымытык торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2023 елда 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге формада белем алучы студентлардан, махсус хәрби операциягә җибәрелгән гаилә әгъзасы булган гаиләләрдән тыш, Тымытык авыл җирлеге Тымытык торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә, 2 төркем инвалидларыннан бер тапкыр түләтүне 200 сумга киметеп, үзара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга җибәрергә:

- Тымытык авылы җирлегенең урам утларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампалар, яктырткычлар, электр товарлары һәм махсус җиһазлар сатып алу, алыштыру, урам утларын ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү);
- Тымытык авылында Бакча урамында вак таш җәелгән юлны ремонтлау һәм карап тоту (вак таш сатып алу, ташу, җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- Тымытык авылында «Җиңү көне», «Сабантуй», «Халыкара өлкәннәр көне», бәйрәм чараларын үткәрү өчен бүләк, сувенир продукциясе сатып алу;
- Тымытык авылы Ленин урамындагы зират территориясендә контейнер мәйданчыгы урнаштыру (коймалар алу өчен материаллар сатып алу, коймалар ясау һәм урнаштыру, контейнер сатып алу һәм контейнер мәйданчыклары урнаштыру (нигезен, коймасын урнаштыру);
- Тымытык авыл җирлеге территорияләрен төзекләндерүне оештыру (килешү буенча эшләр өчен түләү).

3. Әлеге карарны, кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, Тымытык авыл җирлеге мәгълүмати стендларында һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы
Тымытык авыл җирлеге башлыгы Э.Х. Гыйләҗева